РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЛАШЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 27 мае 88-1 номерлы

Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге
җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районы
җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең
бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында
килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше нигезендә Югары Лашчы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Расларга:

- Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен (1 нче кушымта);

- Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Буа муниципаль районы Советына тапшыру турында Килешүнең типлаштырылган формасын (2 нче кушымта);

- Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләрнең үтәлеше турындагы хисап формасын (3 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълумати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Югары Лашчы авыл
җирлеге башлыгы Г.Х. Усманова

Буа муниципаль районы
Югары Лашчы авыл җирлеге Советының
2020 елның 27 маеның 88-1 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешү төзү тәртибен эшләп чыгара һәм Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районыны җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен җайга сала (алга таба - Килешү).

1.2. Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары (алга таба - авыл җирлек) Буа муниципаль районы (алга таба - район) җирле үзидарә органнары ( алга таба- район) белән җирлек бюджетыннан район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына , аларга үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру буенча Килешүләр төзергә хокуклы.

Бу очракта районның җирле үзидарә органнары җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон, район Уставы, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлеккә вәкаләтләрне тапшыру турындагы Килешүләр нигезендә гамәлгә ашыралар.

1.3. Районның җирле үзидарә органнары җирлекнең җирле үзидарә органнары белән үз район бюджетыннан җирлек бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына, аларга үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турында Килешүләр төзергә хокуклы.

Бу очракта районның җирле үзидарә органнары җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон, район Уставы, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлеккә вәкаләтләрне тапшыру турындагы Килешү нигезендә гамәлгә ашыралар.

### 2. Җирле үзидарә органнары компетенциясе

2.1. Җирлек Советы:

1) җирлек вәкаләтләренең бер өлешен муниципаль районга тапшыруның инициаторы;

2) җирлекнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен җирле үзидарә органнарына кабул итү (тапшыру) турында карарлар кабул итә һәм киресенчә;

3) кабул ителгән карарларны тикшерп тота;

4) җирлек тарафыннан кабул ителгән район вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар кабул итә, әгәр Килешүдә башкасы каралмаган булса.

2.2. Җирлекнең башкарма комитеты:

1) вәкаләтләрнең бер өлешен җирлектән муниципаль районга бирүнең инициаторы.

### 3. Җирлек җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләренең бер өлешен район җирле үзидарә органнарына тапшыру.

3.1. Җирлек вәкаләтләренең бер өлешен тапшыруның инициаторы булып Җирлек

җирле үзидарәсе органы була ала.

3.2. Җирлекнең җирле үзидарә органы чираттагы утырышта карау өчен җирлек Советы рәисенә вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында карар проектын җибәрә.

3.3. Вәкаләтләрнең бер өлешен җирлек Советы рәисе тарафыннан гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы карар проекты Югары Лашчы авыл җирлеге Советына карауга кертелә. Җирлек советы вәкаләтләрнең бер өлешен районның җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны район җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә. Җирлек Советы карарында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр составына керүче тапшырыла торган вәкаләтләр күрсәтелә.

3.4. Җирлек Советы тарафыннан карар проектын карауның уңай нәтиҗәсе район Советы карары булганда, район җирле үзидарә органы һәм җирлекнең җирле үзидарә органы арасында Килешү төзелә.

3.5. Әгәр Совет депутатлары вәкаләтләрнең бер өлешен җирле үзидарә органнарына тапшыру турындагы карар проектын кире какса, инициативаны җибәргән җирле үзидарә органнарына үзләре тәкъдим иткән мәсьәләне карау нәтиҗәләре турында хат җибәрелә.

3.6. Килешүдә каралган вәкаләтләр үтәлешен контрольдә тоту, җирлеккә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, финанс чараларыннан (бюджетара трансфертлардан) файдалану турында хисап бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Хисап бирү вакыты килешү белән билгеләнә.

3.7. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

## 4. Җирлек җирле үзидарәсе органнарының район җирле үзидарәсе органнарыннан вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү

4.1. Район вәкаләтләренең бер өлешен алуның инициаторы булып район җирле үзидарәсе тора.

4.2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнарыннан кабул итү инициативасы белән чыгыш ясый алалар. Вәкаләтләрне кабул итү турындагы тәкъдим, вәкаләтләрне тапшыру турындагы мәсьәләне карау өчен, районның җирле үзидарә органнарына җибәрелә һәм күрсәтелгән органнар тарафыннан 30 календарь көннән дә ким булмаган срокта каралырга тиеш.

4.3. Вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдим кабул ителгән очракта, район Советы тарафыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен җирлекнең җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул ителә.

4.4. Кабул ителгән карар Җирлек адресына җибәрелә һәм анда тапшырыла торган вәкаләтләр турында, вәкаләтләрне тормышка ашыруга бирелә торган финанс чаралар турында мәгълүматлар булырга тиеш.

4.5. Совет кабул иткән карар районның җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында мәсьәләне карау уңай кабул ителгән очракта, җирлекнең һәм районның вәкиллекле органнары, билгеле җирлек җирле үзидарәсе органнары һәм район җирле үзидарәсе органнары арасында Килешү төзелә.

## 5. Килешүнең эчтәлегенә таләпләр

5.1. Килешүләр билгеле бер срокка төзелергә, аларның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләрне, шул исәптән вакытыннан алда, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибен, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

5.2. Килешү җирлек һәм район җирле үзидарә органнары өчен имза куелган көннән соң үз көченә керә һәм үтәү өчен мәҗбүри була.

## 6. Килешүнең гамәлдә булуын туктату

6.1. Килешү, ул төзелгән вакыт узганнан соң, гамәлдән чыга.

6.2. Шартлар үтәлмәгән очракта, Килешү, теләсә кайсы як инициатвасы белән өзелергә мөмкин. Килешүне өзү турында хәбәрнамә язма формада, өзү датасына кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, җибәрелергә тиеш.

Буа муниципаль районы
Югары Лашчы авыл җирлеге Советының
2020 елның 27 маеның 88-1 номерлы карарына
2 нче кушымта

Буа муниципаль районы ___________________ авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Буа муниципаль районы Советына тапшыру турында
Килешү

Буа шәһәре «____» __________ 2020 ел

Буа муниципаль районы ____________________ авыл җирлеге Советы, алга таба - "Җирлек Советы" дип аталучы, Буа муниципаль районы _____________________ авыл җирлеге башлыгы ________________________йөзендә, Устав нигезендә эш итүче Буа муниципаль районы Советы , бер яктан,һәм Буа муниципаль районы Советы, алга таба "Район Советы" дип аталучы, Буа муниципаль районы Башлыгының беренче урынбасары Еремеев Илдар Фәрит улы йөзендә, Устав нигезендә эш итүче, икенче яктан, бергә “Яклар” дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.2. Әлеге Килешүнең предметы булып җирлек Советының Буа муниципаль районы составына керүче муниципаль милектәге мөлкәтне файдалану, алардан файдалану һәм алар белән эш итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район Советына тапшыру тора.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Советы район Советына тәкъдим итәргә тиеш:
Әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары (алга таба-вәкаләтләр).
2.2. Җирлек Советы хокуклы:
5.1-5.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә район Советы вәкаләтләренең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту;
Район Советыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүмат алырга.
2.3. Район Советы бурычлы:
законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән җирлек Советы тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан бары тик вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен генә максатчан файдалануны тәэмин итү.;
вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисап бирергә, шулай ук аерым запрослар буенча килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат бирергә.
2.4. Район Советы хокуклы:
Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Советы тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;
вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану.

3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.
3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме _____________ елына сум күләмендә билгеләнә.
3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары бер үк вакытта күчерелә.

3.4. Район Советының финанс чараларын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек Советы таләбе буенча, максатсыз файдалану ачыклганганнан соң, ун көн эчендә җирлек бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерү

4.1. Җирлек Советы вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында район Советыннан кирәкле мәгълүмат сорый. Район Советы җирлек Советы запросы буенча соратып алына торган мәгълүматны бирергә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисап формасы һәм аларны бирү тәртибе җирлек Советының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Бирелгән финанс чараларын тотуны тикшерү Буа муниципаль районы_______________ авыл җирлеге Советы тарафыннан башкарыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Әлеге килешү бер елга төзелгән, яклар кул куйганнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.2. Әлеге килешү бер календарь елга озайтылган дип санала, әгәр якларның берсе дә Килешүнең 5.1 пунктында каралган срок чыкканчы ике ай эчендә өзү турында белдермәсә.

## 6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе.

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

яклар килешүе буенча;

якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, берьяклы тәртиптә.

6.2. Әлеге килешүнең өзелүе турында хәбәрнамә башка якка, аның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге килешүнең гамәлдә булу срогыннан алда туктатылган очракта, район Советы, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән файдаланылмаган финанс чараларын җирлек Советына кире кайтара.

## 7. Яклар җаваплыгы

7.1. Яклар тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык җитүгә нигез булып тора.

7.2. Әлеге килешү буенча Якларның берсенең йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3 Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

## 8. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

Әлеге Килешүнең үтәлеше белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.4. Әлеге Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

10. Яклар имзалары

| | |
|---|---|
| ТР Буа муниципаль районы<br>Башлыгы урынбасары | ТР Буа муниципаль районы<br>______________ авыл җирлеге башлыгы |
| _________________/И.Ф. Еремеев/<br>М.У. | __________________/_____________/<br>М.У. |

Буа муниципаль районы
Югары Лашчы авыл җирлеге Советының
2020 елның 27 маеның 88-1 номерлы карарына
3 нче кушымта

Югары Лашчы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләрнең үтәлеше турындагы хисап формасы

| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме | Җирле үзидарә органына бирелгән акча , мең сумнарда | Җирле үзидарә органына кергән акча, мең сумнарда | Җирле үзидарә органы тарафыннан чыгымнар, барлыгы, мең сумнарда | Файдаланылмаган акчаларның калган өлеше хисап чоры ахырына, мең сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Квартал хисабы

Буа муниципаль районы____________________
авыл җирлеге башлыгы ________________________________
М.У. (Ф.И. Атасының исеме., имза, дата)
________________